| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.01.2020 Баулы шәһәре № 128

Баулы шәһәр Советының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турында» 2019 елның 12 декабрендә кабул ителгән 123нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше турындагы нигезләмәгә таянып, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2019 елның 12 декабрендә кабул ителгән «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджеты турында» 123 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 статьяның 1 пунктындагы 1, 2, 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 77428,3 мең сум;

2) «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 79890,6 мең сум;

3) «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгы 2462,3 мең сум күләмендә.».

1нче, 5нче, 6нчы кушымтаның 1нче таблицаларын яңа редакциядә 1нче, 2нче, 3нче, 4нче кушымталар нигезендә бәян итәргә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы рәисе

АППАРАТ СОВЕТА СОВЕТ АППАРАТЫ

Р.Х. Гатиятуллин